МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.03.2023 Казан ш. № 212-пр

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 12.08.2022 № 496-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 12.08.2022 № 496-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәкъдим ителгән административ регламентына үзгәрешләр кертү турында.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне әлеге боерык белән расланган Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. 2023 елда дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә 2022 елда җир мөнәсәбәтләрен көйләү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге № 629 карары белән (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 30 декабрендәге № 2536 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелүен гамәлгә куярга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
29.03.2023 № 212-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 12.08.2022 № 496-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәкъдим ителгән административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.5. Әлеге Регламентның 2.3.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсен гариза бирүче Министрлыктан шәхсән үзе алырга хокуклы.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.6 пунктны өстәргә:

«2.3.6. Җир кишәрлеген түләүсез милеккә бирү турында карарлар Министрлык карары рәвешендә кабул ителә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.7 пунктны өстәргә:

«2.3.7. Җир кишәрлеген түләүсез милеккә бирү турында карар реквизитлары (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында):

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (территориянең кадастр планында җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында карарны электрон имза белән имзалаганда).»;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.4 пунктны өстәргә:

«2.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче күрсәткән ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.»;

2.6.6 пунктта:

3 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (алга таба – РФ ПФ) инвалидлык турында белешмә (инвалидлык төркемен күрсәтеп, инвалидлык билгеләнүен раслаучы белешмә; инвалидны, инвалид баланы реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы), мәгълүмат «Инвалидларның Федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмати системасында (ФГИС ФРИ) булырга тиеш, гражданин (торакны яллаучы) инвалид булса яки аның гаиләсе составында инвалид булса (хезмәт торагын махсус торак фондыннан чыгарган очракларда).»;

4 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында (алга таба – РФ ХК) билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә (2020 елның 1 гыйнварыннан соңгы чор өчен) Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан яки Гариза бирүченең соңгы эш урыны буенча эш бирүчедән (гражданнар өчен).»;

2.7 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге Регламентның 2.5.1 – 2.5.2 пунктлары нигезендә гариза бирүче үзе бирергә тиешле документларның тапшырылмавы;»;

алтынчы абзацны көчен югалткан дип танырга;

2.11.3 пунктта «җибәрелгән» сүзен «алынган» сүзе белән алмаштырырга;

2.14.6 пунктта:

беренче абзацка «язылу)» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацка «Гариза бирүче» сүзеннән соң «Министрлыкта» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Алдан язылмау гариза бирүчегә чират тәртибендә мөрәҗәгать итергә комачауламый.»;

3 бүлектә:

3.4.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;»;

3.5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.»;

3.6.1 пунктның икенче абзацында слова «2.6.2 пунктта» сүзләрен «2.6.1, 2.6.2 пунктларда» сүзләре белән алыштырырга;

3.6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. Бүлек белгече гариза Бердәм портал, Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә.

Гариза керүе турында электрон хәбәр һәм гаризаның регистрацияләнүе турында белдерү Бердәм портал, Республика порталындагы шәхси кабинетта үтенеч язуы каралу статусында автомат рәвештә чагыла.»;

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат һәм логик яктан тикшерү гариза бирүче запросның электрон формасындагы һәр юлны тутырганнан соң Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал запросның электрон формасындагы юлының дөрес тутырылмавын ачыкласа, гариза бирүчегә запросның электрон формасы өстендә үк мәгълүмати хәбәр буларак, ачыкланган ялгыш һәм аны төзәтү тәртибе турында белдерелә.»;

3.6.2.3 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.»;

сигезенче, тугызынчы, унынчы абзацларны көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Бүлек белгече “Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау” административ процедурасын башкаруга күчә.»;

3.6.3 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган

документларны кабул итүдән язмача баш тарту, гариза бирүчегә кайтарылган документлар.».

3.6.4 пунктның җиденче абзацында «сәбәпләре күрсәтелеп» сүзләрен: «документларны кабул итүдән язмача баш тартып» дип алмаштырырга;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау»;

3.7.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.1. Запрос җибәрү өчен нигез булып гариза бирүченең регистрацияләнгән гаризасы тора.»;

3.7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.2. Бүлек белгече эш башкару бүлегеннән гаризаны һәм документларны алгач, “Гаризаның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыганнан үтү битен” (әлеге Регламентка 7 нче кушымта) тутыра һәм ведомствоара электрон арадашлык системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) электрон формада әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документларны һәм мәгълүматны бирү турында запрослар юллый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле соралган документлар исемлеге::

1. Соралган җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә. Запрос ТР буенча ФКПга юллана.

2. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат турында яисә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан шәхси эшмәкәр турында өземтә. Запрос ТР буенча ФСХИга юллана.

3. Инвалидлык турында белешмә (инвалидлык төркемен күрсәтеп, инвалидлык билгеләнүен раслаучы белешмә; инвалидны, инвалид баланы реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы), мәгълүмат «Инвалидларның Федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмати системасында (ФГИС ФРИ) булырга тиеш, гражданин (торакны яллаучы) инвалид булса яки аның гаиләсе составында инвалид булса. Запрос РФ ФПССка юллана.

4. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә. Запрос (2020 елның 1 гыйнварыннан соңгы чор өчен) РФ ФПССка яки гариза бирүченең соңгы эш урыны буенча эш бирүчегә (гражданнар өчен) юллана.

5. Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаучы документларны раслау турында» 2020 елның 2

сентябрендәге № П/0321 Боерык белән расланган документлар исемлегендә каралган башка документлар һәм белешмәләр. Запрос дәүләт хакимиятенең вәкаләтле федераль органына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына юллана.

Ведомствоара мәгълүмати запрослар күрсәтелгән органнарга гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар регистрацимяләнгән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар.»;

3.7.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.3. Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин түгел;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомоствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның $7^2$ статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомоствоара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе).

Административ процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченең соралган документларны (күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), яки баш тарту турында хәбәрне алуы.

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.»;

3.9.3 пунктта:

икенче абзацны «(әлеге Регламентка 6 нчы кушымта)» сүзләре белән тулыландырырга;

өченче абзацка «нәтиҗә» сүзеннән соң «күрсәтү» сүзен өстәргә;

3.9.5 пунктның беренче абзацында «җир кишәрлеген һәм» сүзләрен «җир кишәрлеген яки» сүзләре белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $3.9.5^1$ пункты белән тулыландырырга:

«$3.9.5^1$. Бүлек мөдире Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән җир кишәрлеген бирү турында карар проектын яки баш тарту

турында карар проектын хокукый экспертиза уздыру өчен хокук идарәсенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, алдагы процедура беткән көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, хокук идарәсенә юлланган җир кишәрлеген бирү турында карар проекты яки баш тарту турында карар проекты.»;

3.9.7 пунктның икенче абзацында «алдагы процедура беткәннән соң» сүзләрен «әлеге Регламентның 3.9.5[1] пункты белән каралган процедуралар беткәннән соң» сүзләре белән алыштырырга;

3.9.9 пунктның икенче абзацында «алдагы процедура беткәннән соң» сүзләрен «әлеге Регламентның 3.9.6, 3.9.7 пунктлары билгели торган процедуралар беткәннән соң» сүзләре белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.9.13 пункт белән тулыландырырга:

«3.9.13. Регламентның 3.9.3 – 3.9.12 пунктларында күрсәтелгән процедураларны башкару, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып автомат режимда гамәлгә ашырыла.»;

3.10.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе гариза бирүчегә үзе сайланган ысул белән бирелә (җибәрелә):»;

3.12.3 пунктның икенче абзацында «гариза регистрацияләнгән бер эш көнендә» сүзләрен «гариза кергән көндә» сүзләре белән алыштырырга;

3.12.4 пунктта:

беренче абзацны «дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә үзгәрешләр проекты әзерли» сүзләре белән тулыландырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедура нәтиҗәсе булып тора: гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) үзгәрешләр кертелгән документ.».

Регламентка 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

___________________________________________

___________________________________________

(физик затлар өчен - фамилия, исем һәм (булганда) әтисе исеме, яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары)

___________________________________________

(юридик затлар өчен - атамасы, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы, ОГРН, ИНН, чит ил юридик заты гариза бирүче булган очраклар искәрмә булып тора)

___________________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү турында
гариза

_____________________________________________________________________

____________________________________________________нигезендә

(РФ ЖК $39^5$ ст. каралган нигезләр арасыннан тиешлеләре күрсәтелә)

__________________________________________________________өчен

(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)

______ кадастр номерлы ___________ кв.м мәйданлы, рөхсәт ителгән төре________________булган ___________________, _______________җир категориясеннән, _______________________________адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген милеккә түләсез бирүегезне сорыйм.

Өстәмә мәгълүмат (түбәндә күрсәтелгән шартлар булганда тутырыла): ______________________________________________________________________

җир кишәрлеге дәүләт ихтыяҗы өчен тартып алынган җир кишәрлеген алыштырып бирелгән очракта җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗы өчен тартып алу турында карар реквизитлары;
______________________________________________________________________

соралган җир кишәрлеге ясалган булса яки аның чикләре әлеге карар нигезендә төгәлләштерелгән очракта җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар реквизитлары

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- җибәрергә _____________________________________________________;

(күрсәтелә: МФЦга - электрон документ формасында, электрон документның кәгазьгә төшергән экземплярын; Бердәм порталга, Республика порталында шәхси кабинетка);

- Министрлыкта бирергә ____________________

____________________________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь документ, электрон документ формасында яки электрон документның кәгазьгә төшерелгән экземплярлары)

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтен бәяләү буенча телефон буенча сораштыруга ризалыгымны бирәм: ______________________.

«__»______20___ел __________________ (_______________________)
(дата) (имза) (фамилия, исеме һәм (булса) әтисе исеме

М.П. (булса, юридик затлар өчен)